Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге Советы Карары

«30» октябрь 2020 ел № 6

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 20.06.2012 ел, № 40/1 карары белән расланган Муниципаль хезмәт турында" Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Олы Әтнә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 20.06.2012 ел, № 40/1 карары белән расланган Муниципаль хезмәт турында " Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 15 статьяның 15.3 пунктының 4 пунктчасында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр " сүзләрен өстәргә;»

**1.2.** 28 статьяның 28.1 пунктындагы 4 пунктына "(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмати ресурсларында саклау өчен " (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне тапшыру" сүзләрен өстәргә

**1.3**. 15 статьяның 15.3 пунктының 6 пунктчасында " мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы "сүзләрен" индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ "сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (pravo.tatarstan.ru ) веб –адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы
вазифасын вакытлыча башкаручы Р. Р.Маликова